ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2024 п.г.т Алексеевское № 531

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 27.12.2023 ел, № 635 «2024 елга Алексеевск муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифлар турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Рәисенең «2024-2028 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнар тарафыннан кертелә торган коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» 2023 елның 15 декабрендәге 867 номерлы Указына туры китереп,

**карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 27.12.2023ел, № 635 «2024 елга Алексеевск муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифлар турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче номерлы кушымтаны (кушымта) яңа редакциядә бәян итәргә

«Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урынны карап тоту өчен түләү күләме һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләме».

2. Баш мөхәррир Е.Д. Ахманаевага әлеге карарны «Заря» (Таң) район газетасында бастырып чыгарырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтына http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.С. Язынинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
27.11.2024 ел, № 531
карарына кушымта

**Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урынны карап тоту өчен түләү күләме, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен һәм гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләме.**

| № | Хезмәт исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүнс үлчәү берәмлеге өчен тарифлар (сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 01.01. 30.06. | 01.07. 31.12. |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | торак урынның гомуми мәйданының аена кв. м | 3,40 | 3,71 |
| 2 | Йорт яны территориясен җыештыру һәм ишегалдын карап тоту | торак урынның гомуми мәйданының аена кв. м | 2,15 | 4,90 |
| 3 | Торак биналарны агымдагы ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданының аена кв. м | 3,67 | 4,0 |
| 4 | Йорт эчендәге инженерлык җайланмаларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау:<br>-йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм су түгү санитария-техник челтәрләре | торак урынның гомуми мәйданының аена кв. м | 1,85<br>- | 2,02<br>- |
| 5 | Торак йортларда йорт эчендәге газ | торак урынның гомуми | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | челтәрләренә һәм йорт эчендәге газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү | мәйданының аена кв. м | 0,43 | 0,47 |
| 6 | Электр белән тәэмин итү челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү | торак урынның гомуми мәйданының аена кв. м | 1,09 | 1,19 |
| 7 | Вентканалларга һәм төтен чыгаргычларга техник хезмәт күрсәтү | торак урынның гомуми мәйданының аена кв. м | | 0,35 |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.Ю. Йосыпова**